ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№_237___ «_06_»___03________2017 ел

Мамадыш муниципаль районы
Башкарма Комитет җитәкчесенең
2013 елның 18 сентябрендәге «Мәктәпкәчә
белем бирү программасын гамәлгә ашыручы
белем бирү оешмаларына йөрүче балалары
булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары
күрсәтү турында»1333 номерлы карарына
үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2017 елның 8 февралендәге керемнәрне исәпләүнең төрле механизмнарын куллану белән бәйле гражданнар мөрәҗәгатьләре санын киметү, балалы гаиләләргә социаль ярдәм күрсәтүнең адреслы чараларын билгеләгәндә, мәктәпкәчә белем бирү оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга өстәмә компенсация бирү һәм балага айлык пособие бирү тәртибен унификацияләү, компенсация түләүләре бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында 20-13/1392 номерлы хаты нигезендә, шулай ук Мамадыш муниципаль районында республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәгенең 27 нче филиалы эшен оештыру максатларында, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты **карар бирә:**

1. Мамадыш муниципаль районы комитеты җитәкчесенең «Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында» 2013 елның 18 сентябрендәге 1333 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1 Бүлек. Гомуми нигезләмәләр:

1.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Компенсация алу хокукын билгеләгәндә гаиләнең җан башына уртача кереме Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында халыкның аерым категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында 2004 елның 17 декабрендәге 542 номерлы карары белән расланган «Балага айлык пособие билгеләгәндә гаиләнең җан башына уртача keремен исәпләү тәртибен раслау һәм халыкның

аерым категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2016 елның 10 сентябрендәге 625 номерлы карары белән билгеләнгән кагыйдәләр буенча исәпләнә»,»;

«Компенсация билгеләү өчен гаиләнең уртача керем айга кадәрге соңгы алты календарь айны алып, барлык кирәкле документлар белән компенсация билгеләү турында гариза биргән айда билгеләнә (алга таба - хисап чоры)».

2 бүлек. Компенсация билгеләү һәм түләү тәртибе:

2.1 пунктның b) пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә**:** «өстәмә компенсация бирү турында гариза бирелгән айга кадәрге алты айда гаиләнең һәр әгъзасы керемнәре турында документлар»;

2.1 пунктның k) пунктчасына абзац өстәргә: «Махсуслаштырылган оешмага Россия Федерациясе Пенсия фондыннан, шул исәптән ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасын һәм аңа тоташтырыла торган ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлекнең төбәк системаларын кулланып, түләүләр суммасы һәм физик зат файдасына эш бирүче (страховкалаучы) тарафыннан исәпләнгән башка бүләкләүләр турында мәгълүмат алу мөмкинлеге бирә торган мәгълүмати хезмәттәшлек кертелгәннән соң, аның гаризада күрсәтелгән ризалыгы белән компенсация билгеләү, Россия Федерациясе Пенсия фондында булган мәгълүматлар нигезендә, мөрәҗәгать итүче билгеләгән өчен мөрәҗәгать иткән айга кадәрге соңгы 6 айда 12 айдан, аның ризалыгы белән компенсация түләнә.».

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны муниципаль район Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А.П. Смирновага йөкләргә.

Җитәкче И.Э. Фәттахов